**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 6 июнендәге 2333 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 27 сентябрендәге 2457 номерлы «Вахитов районының Мәҗит Гафури урамындагы җир кишәрлекләре өлешләрендә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан электр челтәрләре – «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте филиалының Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 27 сентябрендәге 2457 номерлы «Вахитов районының Мәҗит Гафури урамындагы җир кишәрлекләре өлешләрендә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кетү хакындагы гаризасы, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 27 сентябрендәге 2457 номерлы «Вахитов районының Мәҗит Гафури урамындагы җир кишәрлекләре өлешләрендә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. 7.1 пунктчаны гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**